**Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.): «Шигырьдә хикмәт бар»**

# Күңелкәйләр сагына әткәемне...

Быелгы март ае нәселебезгә бик зур югалтулар алып килде. Минем кадерле әтием 82 яшендә вафат булды.

Әткәй актив кешеләр исемлегендә булды.

Ульян өлкәсенең Кулатки районында урнашкан Иске Мостяк авылында Югары Оч мәчетен төзүгә зур өлеш кертте.

Һәм шул мәчеттә күп еллар имам-хатыйб вазыйфасын үтәде. Аны, Хәсән углы Сөләйман Әбдерәшитовны, соңгы юлга авылдашларыбыз хөрмәт белән озаттылар.

Ул балалары, авылы, аның халкы, динебез Ислам өчен янып-көеп яшәде.

Аллаһыма мең-мең шөкранамын. Әтиемнән читтә яшәсәм дә, актык көннәрендә мине аның янында булдырганына.

Әтием-бәгырем, урының җәннәттә булсын.

Без СИНЕ нур, изгелек сипкән кеше буларак, күңел түребездә саклыйбыз.

Аллаһы теләсә, догада булырбыз.
Намазларыбыздан калдырмабыз.

**Сөләйман кызы Наилә ХӨСӘЕНОВА.**

Әтием исән чакта язылган шигъри хисләрем.

**Алтын бөртекләрем**

Әти-әни - алтын бөртек,
Тормышымны бизәп торган,
Безнең өчен үреп наздан,
Күңелемдә бишек корган.

Әти-әни - изге җаннар,
Миңа гомер биргән алар,
Йөрәгемә иман нуры
Һәм дә шәфкать нуры салган алар.

Әткәй-әнкәй - изге җаннар,
Хәятем бит Сезнең җанда,
Нарасыйдай күңел изрәр
Балам, диеп, Сез кочканда.

Әткәй - аем, әнкәй - кояш,
Дөнйа күге асыллары,
Гомер күгем офыклары
Һәм җәннәтнең ачкычлары.

Узганнарга түзү кирәк,
Сез бит миңа - көчле терәк,
Һәр таң саен азан белән
Сезнең янга кайта йөрәк.

Әткәй-әнкәй - рухи канат,
Йөрәгемә сеңгән хикмәт,
Тәңремә мәңге рәхмәт,
Сез бит миңа - олуг нигъмәт.

Әтием үлгәч язылган юллар.

**Аҗагандай булдың, әткәем...**

Юк син, әткәй...
Инде миңа каршы чыкмассың,
Шатлыгым вә куанычым диеп,
Мәңге мине сөеп кочмассың.

Ходаемның миңа бүләгедер -
Гомереңнең актык көннәрен

Чәйләр эчеп бергә үткәрдек,
Сизмәдек бит: бу мизгелнең соңгы икәнен.
Юк син, әткәй...
Син кайтмассың...
Тик шулай да йөрәгемдә җылы сулышларың
Яшәү дәрте булып янасың.

Бәхетебез безнең кыска булды,
Бер аерды язмыш, бер үлем,
Җәннәтләрдә урның булсын диеп,
Дога укып сорыйм мин бүген.

**Сөләйман кызы Наилә ХӨСӘЕНОВА.**
Самар - Иске Мостяк.
Март. 2013 ел.

**Наилә ханымның хәсрәтле айларында Ходай Тәгаләдән: "Сабырлык бирсәң иде", - дип сорыйбыз.**

**Исәннәрнең авазын мәетләр ишетәме?**

Пәйгамбәребез (с.г.в.) Бәдер сугышыннан соң, мөшрикләрнең башлыгы булып сугышта үлгән Әбү Җәһил һәм аның дуслары янына килеп: "Аллаһы Тәгалә безгә вәгъдә кылган иде, сез дә ирештегезме?" - дип, аларның үле гәүдәләренә карап әйтте.

Бу сүзләрне ишетеп, Гомәр (р.а.г.): "Әй, Аллаһының илчесе, бу мәетләрнең рухлары юк бит, син аларга нигә эндәшәсең?" - дигәч:

"Мәетләр тере кешеләрнең сүзләрен ишетәләр, җавап кына бирә алмыйлар", - дип җавап кайтарды.

* * *




**Мөхәммәд Пәйгамбәр әйтте**

## "Дуңгыз аягы астына сипмәгез"

Пәйгамбәребез (с.г.в.) бер хәдисендә:
"Энҗене (жемчуг) дуңгыз аягы астына сипмәгез, ягъни теләмәгән кешегә аңлатып, азап чикмәгез, вакытны сарыф итмәгез", - дигән.

———————————————

**Галимнәр фикере**

## Иң дөрес дин - татарда

Халкыбызның атаклы галиме, татарның мәшһүр шәхесе Каюм Насыйри язып калдырган: "Иң дөрес дин сакланып калган татарларда".

* * *

**Авыз әдәбе**

# Ашагач, авызыгызны яхшылап чайкагыз

Мәҗлесләрдә, хосусан туй вә шатлык мәҗлесләрендә булган вакытыгызда көлүдән вә гадәттән тыш уен-көлке сөйләүдән сакланыгыз. Бәлки, үзегезне тота белеп вә сабыр гына, ачык йөз белән булыгыз!

Хәсрәтле вә ачулы кеше йөзенә көлмәгез һәм хәсрәтле бәндәләргә күңелләрен бастырырлык нәрсәләрдән башка сүз сөйләмәгез!

Мөмкин булганда адәмнәр алдында кикермәгез, кулыгыз яки яулыгыгыз белән пәрдәләнмичә торып, авыз ачып иснәмәгез. (Авызга зарарлы микроблар кермәсен өчен, шулай каплау тиештер.)

Авызыгызны ачып, тешләрегезне казымагыз.

Авыз ачып иснәгәндә вә ютәлләгәндә дә сөйләшмәгез, бәлки, бу вакытларда йөзегезне бер тарафка юнәлдерегез!

Әгәр дә авыз ачып иснәү вә ютәлләү кат-кат булса, башкаларга рәхәтсезлек итмәс өчен мәҗлестән чыгып торыгыз!

Сөйләшкән вакытыгызда авызыгыздан төкерек чәчмәгез.

Кулларыгызны һавада йөртмәгез.

Берәүнең сүзе тәмам булмастан элек сүзгә керешмәгез!

Җиргә вә кешеләргә төкерүдән, какырудан сакланыгыз, бәлки, моның өчен янгыгызда кульъяулык булдырыгыз!

Суган, сарымсак ашап вә яки башка нәрсәләр белән авызыгызны ислән-дермәгез!

Һәркөнне иртән, хосусан тәһарәт алган вакытыгызда һәм ашаганнан соң, авызыгызны яхшы чайкагыз.

Теш арагызда ризык калдырмагыз.

Теш щеткасы белән камил чистартыгыз!

**Ризаэтдин ФӘХРЕТДИН.**

———————————

**Сәламәтлек**

# Каты тавышлар колак өчен зарарлы

Җәнабе Аллаһы колакларны файдалы нәрсәләр ишетү өчен яраткандыр.

Шуның өчен алар белән Коръәни-Шәриф вә мөбарәк хәдисләр, гыйбрәтле сүзләр ишетеп, гамәл кылыгыз.

Ата-ана вә остазларыгызның нәсыйхәтләрен тыңлагыз!

Бозык сүзләр ишетү гакылларга бозыклык китерер.

Шуның өчен яман сүзләр ишетмәгез.

**Яшеренеп сөйләнә торган сүзләрне тыңлап йөрмәгез!**

Һичкемнең күңеле исә моңа риза булмас.

Сүз йөртүчеләр вә гайбәт сөйләүчеләрне тыңламагыз, күзегезне түбән салып тик торыгыз, үзегез белән бертигез булсалар - мондый эшләрнең яраклы түгеллеген әдәп белән аңлатыгыз,

үзегездән кечкенәләр булганда, мәрхәмәт белән генә тыегыз.

Ишеткән сүзләрдән фетнәгә сәбәп булачакларын һичкемгә сөйләмәгез!

Әдәпсез урыннарга барып, гөнаһка төшәчәк рәвештә уен тавышларын тыңламагыз!

Колакларыгызны һәрвакыт, хосусан йокыдан торгач пакьләп, мөмкин булганда моны пакьләр өчен фил сөягеннән ясалган колак казыгычны янгыгызда булдырыгыз!

Йөзегезне юганда колакларыгызның эчләрен вә тышларын юыгыз һәм тастымал белән корытыгыз!

Каты тавышлар колак өчен зарарлы булганга күрә, алардан мөмкин кадәр ерак булыгыз!

**Ризаэтдин ФӘХРЕТДИН.**

# Совет улемов (ученый совет) при РДУМСО активизирует свою деятельность

В последнее время активизируется деятельность РДУМСО. Ставятся конкретные задачи, от решения которых зависит многое:

- успешность развития мусульманских сообществ в будущем;
- их моральный и нравственный облик;
- сохранение и развитие национально-культурного достояния и духовного содержания татарского общества;
- стабильность и взаимопонимание между различными мусульманскими сообществами в регионе.

На ученом совете были поставлены следующие вопросы:

1. Поднять авторитет и активизировать деятельность мусульманских сообществ на местах (махалли).

2. Укреплять связи между администрациями сел, школами и местными мусульманскими организациями (махалля).

3. Организовать досуг детей и подростков на каникулах и в выходные дни, а так же организовать курсы по изучению основ Ислама и мусульманской этики.

4. Разработать единую программу обучения детей основам Ислама.

5. Совершенствовать систему организации летнего оздоровительного лагеря для детей и подростков.

Одним из мощных стимулов при воспитании молодежи является волонтерство.

В связи с этим необходимо:

1. Определить основные направления деятельности волонтеров (сбор и раздача вещей нуждающимся, организация очистки территорий мечетей и кладбищ, шефство над приютами, детскими домами и оказание различных услуг)

2. Создать базу данных о лицах, семьях и учреждениях, которые нуждаются в помощи и поддержке.

3. Координирующим центрам волонтерского движения установить прочные связи с руководителями местных мусульманских организаций и имамами мечетей для выявления лиц и объектов, нуждающихся в помощи. Ибо имамы больше других информированы о нуждах людей и состоянии их семей.

Безусловно, имеется много проблем на пути решения вопроса о духовно-нравственном оздоровлении общества. Однако и в нашем регионе есть интересный опыт и поучительные примеры, где активную позицию занимают мусульманские лидеры. Например, в Камышлинском и Похвистневском районах.

К сожалению все еще присутствует дух атеизма – наследие советской эпохи. Школа и религиозная община – это две базы, на ком лежит ответственность за воспитание будущих граждан и формирование их общественного сознания. Однако, между ними существует невидимая преграда, которая мешает решать общие проблемы. А местные органы власти не в состоянии объединить их усилия в единое русло. Это сложная задача. Ее нельзя решить одномоментно, приказами или вынесением конкретных постановлений. Здесь должен срабатывать решительность при использовании полномочий, предоставленных властями и обществом. Тут главными направляющими должны быть гражданская позиция, чувство ответственности за будущее общества, которое тебя взрастило. Это, конечно, в первую очередь касается глав местных организаций, имамов мечетей, представителей мусульманских общин и директоров школ.

Однако тут еще должна срабатывать и активная позиция мусульманского сообщества – махалли. Повышение его активности означает обеспечение нормального развития данного населенного пункта в будущем. Хочется верить, что в дальнейших заседаниях совета улемов будет уделено особое внимание решению этих вопросов и задач.

**Фарид ШИРИЯЗДАНОВ.**